# КАРАР

**2022 елның 25 ноябре** **№ 1**

**«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Югары Кузмесь авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә 3 этапта түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Югары Кузмесь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Кузмесь авылының Яшел урамында юлга вак таш җәю; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге генераль планын эшләү; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Югары Кузмесь авылы Яшел урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә;
- светодиод лампалар сатып алу?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

2022 елның 25 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 254 кеше.

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 213 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 109.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен җыенда катнашкан 107 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Югары Кузмесь авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Югары Кузмесь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокл ы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Кузмесь авылының Яшел урамында юлга вак таш җәю; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге генераль планын эшләү; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Югары Кузмесь авылының Яшел урамына балалар мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документлары һәм техник күзәтүне гамәлгә ашыру;
- Югары Кузмесь авылы Яшел урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә;
- Югары Кузмесь авылының Яшел урамына янгын гидранты өчен будка урнаштыру; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелеген гамәлгә ашыру;
- Югары Кузмесь авылының Яшел урамына чишмәгә будка урнаштыру; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелеген гамәлгә ашыру;
- Югары Кузмесь авылы урам юл челтәрен карап тоту; кышын юлларны кардан чистарту; ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- светодиод лампалар сатып алу?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев